

*Әссәламv галәйкvм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтvһ, хөрмәтле дин кардәшләрем, газиз ватандашларым!*
Россия Федерациясе моселманнарынын Үзәк диния нәзарәте исеменнән, шәхсән vземнен әтрафымнан сезне мобарәк Ид-әль-Фитр Ураза гаете бәйрәме унаеннан ихлас кvнелемнән тәбрик итәм!

Таннан алып кояш баеганча, Рамазан шәриф ае буе ураза аркылы vз-vзебезнен нәфесләребез белән сугышып, Аллаһы Тәгалә кушканнарын vтәп, тойганнарыннан тоелып, тоннәре җәмәгать белән мәчетләрдә Аллаһынын илчесе Мохәммәд галәйһи сәламнен таравих соннәт гамәлләрен vтәп ике доньянын бәхетенә, сәгадәтенә ирешербез дип, Аллаһы Раббыбыз тарафыннан әҗер вә саваб белән бvләкләнербез дип, ныклы ышаныч белән Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылып даими рәвештә догада калабыз. Кvп милләтле һәм кvп динле илебез халкына Аллаһы Раббыбыз бәрәкәт һәм сәкинә, ил-коннәребездә тынычлык, иминлек бирсен!
Россия Федерациясе Президентына В.В.Путинга, Мордовия Республикасы Башлыгына А.А.Здуновка, дәvләт тvрәләребезгә Аллаһы Раббыбыз дәvләтебез белән сәяси идәрә итvдә зирәк зиһен, камил акыл, кvркәм холык, унышлар бирсен! Ватанпәрвәрләребезгә, хәрбиләребезгә махсус хәрби операциядә дошманнарыбыз остендә остенлек һәм жинv бирсен!

*Барчагызга да зур ихтирам, хәер дога, кайнар сәламләр белән,*

*Мордовия Республикасында Россия Федерациясе мөселманнарынын*

*Үзәк диния нәзарәты тулы хокуклы вәкиле* ***Рафаэль МАНЮРОВ***